УДК 929

# БАГЪБОСТАН МӨЭМИНОВА ҺӘМ АНЫҢ ОРЕНБУРГТАГЫ КЫЗЛАР МӘКТӘБЕ (ИКЕНЧЕЛ АНАЛИЗ МАТЕРИАЛЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ)

***А.Ә. Зиннәтуллина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*jamash.00@mail.ru*

Мәкалә күренекле мәгърифәтче, татар хатын-кызлары арасында аң-белем таратуда зур өлеш керткән мөгаллимә Мөэминова Багъбостан Вилдан кызының тууына 140 ел тулу уңаеннын тәкъдим ителә. Б.В.Мөэминова Беренче Россия революциясеннән соң Оренбург шәһәрендә беренче җәдиди кызлар мәктәбе ача. Мәктәп 1908–1918 еллар дәвамында эшләп, соңыннан шәһәр карамагына күчерелә. Әлеге мәктәпне тәмамлаган 149 кыз укытучы һөнәрен сайлый. Багъбостан ханым татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән буларак, 1913 елда Мөселман Диния назәрәтендә имтихан тотып, мөгаллимәлеккә шәһадәтнамә ала. Уку-укыту эшләре белән танышу өчен, 1914 елда Төркиягә бара, анда Милләт мәҗлесе утырышында чыгыш ясый. XIX–XX гасырлар кичешендә Оренбург губернасының Кабан авылында Гани Хөсәенов башлап җибәргән мөгаллимәләрнең белемен арттыру өчен җәйге курсларны торгызып, 1916–1917 елларда аның мөдирәсе була. Оренбург мөслимә ханымнары җәмгыяте, Багъбостан ханым мәктәбенең ун еллык юбилее мөнәсәбәте белән, «Ун еллык гыйльми хезмәт» исемле китап бастырып чыгара. Мәкаләдә әлеге китаптан өзекләр бирелә. Аларда мөгаллимә ханымның эшчәнлеге, мөселман хатын-кызлары арасында мәгърифәт тарату һ.б. мәсьәләләр карала, Кырымдагы кызлар мәктәбе мөгаллимәсе Һөрмез Мөхәммәдованың мөгаллимәләр курсы турындагы истәлекләре, Багбостан ханым турында төрек газетасы «Тасфире әфкяр»дә басылып чыккан мәкалә тәкъдим ителә.

**Ачкыч сүзләр:** Багъбостан ханым, хатын-кыз мәгарифе, мөгаллимәләр курсы, Акмәчет, Оренбург, Кырым, Оренбург мөслимә ханымнар җәмгыяте.

Мөэминова Багъбостан Вилдан кызы (1884–1963) – XX гасыр башы татар милли мәгарифе үсешенә зур өлеш керткән күренекле мәгърифәтче, 1905 елгы Россия революциясеннән соң Оренбургта беренче җәдиди кызлар мәктәбе ачкан һәм Кабан авылында[1] мөгаллимәләр хәзерләү курслары оештырган мөгаллимә, татар вакытлы матбугаты битләрендә хатын-кызларның иҗтимагый тормышта һәм гаиләдә тоткан урынын, тәгълим-тәрбия темаларын яктырткан мәкаләләр авторы.

[1] Хәзер Оренбург өлкәсенең Сарыкташ районына керә.

© *Зиннатуллина А.А., 2024*

Багъбостан ханым 1884 елда Татарстанның хәзерге Азнакай районына кергән Мәндәй авылында дөньяга килә. Төрле сәбәпләр аркасында, тиздән гаилә Оренбургка күченеп китәргә мәҗбүр була. Монда кыз яңа ысул белән укытуга нигезләнгән Фатыйма Әдһәмова[2] мәктәбендә белем алып, үзлегеннән күп кенә дөньяви фәннәрне үзләштереп, тирән белемле, алдынгы карашлы, киң фикерле шәхес булып формалаша (Кудаш, 1984: 164–165).

Аң-белемгә тартылган кыз үзе дә балалар укытырга хыяллана. 1908 елда Оренбург шәһәрендә ул ире Гобәйдулла Рәдүди[3] һәм остазы Ф.Әдһәмова булышлыгы белән кызлар мәктәбе ача һәм анда күп еллар дәвамында мөдирлек итә. Уку йорты «Багъбостан мәктәбе» исеме белән таныла. Мөгаллимә ханым төрле каршылыкларга карамыйча, мәктәпнең укыту программасын елдан-ел киңәйтә бара, анда төп фәннәр белән беррәттән, кул эшләренә дә зур әһәмият бирелә, ә инде укыту эшенә кызыксынулары булган соңгы сыйныф кызларына укытучы һөнәре үзләштерү мөмкинлеге дә тудырыла. Нәтиҗәдә мәктәпнең даны бик тиз еракларга таралып, бирегә белем алырга илнең төрле төбәкләреннән мөселман (татар, башкорт, казакъ, үзбәк, кыргыз) кызлары килә башлый.

Багъбостан ханым белемен баету, башка җирләрдә эшләп килгән кызлар мәктәпләренең эшчәнлеге, мөселман халыкларының тормыш-көнкүреше белән танышу максатыннан берничә ел рәттән төрле төбәкләргә сәяхәт итә. Алар арасында иң кызыклысы һәм иң әһәмиятлесе – 1914 елның җәендә Төркиягә баруыдыр, мөгаен. Ул Төркиянең күп кенә шәһәрләрендә булып, уку-укыту эчтәлеген өйрәнә, төрек хатын-кызлары оешмаларында, махсус ханымнар өчен чыга торган журнал нәшриятендә була, мөселман хатын-кызларыннан беренче кеше буларак, фәкать ирләр катнашында гына уза торган Милли Мәҗлес утырышына керергә рөхсәт алып, хатын-кызларны борчыган проблемаларны күтәрә.

Сәяхәтләрнең нәтиҗәсе буларак, мәктәпнең уку-укыту программасы тагын да камилләштерелә һәм укучылар саны тагы да арта. Ун ел эчендә мәктәпне барлыгы 1212 кыз бала тәмамлый. Шулай итеп, Багъбостан ханымның тырышлыгы һәм үҗәтлеге нәтиҗәсендә башлангыч мәктәп буларак ачылган уку йорты 1918 елга гимназия югарылыгына күтәрелә.

Мәктәп тоту белән бергә, Багъбостан ханым Кабан авылында кайчандыр Гани бай[4] башлап җибәргән мөгаллимәләрнең белемен күтәрү курсларын торгызу эшенә дә алына һәм ике ел рәттән аның мөдирәсе була. Бу курсларга, Оренбург авылларыннан кала, Себер һәм Төркестан, Кырым һәм Кавказдан күп

---

[2] Адамова (Әдһәмова) Фатыйма Миркамали кызы – Оренбургта яңа ысуллы татар кызлар мәктәбе мөдирәсе, I Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтае делегаты.

[3] Гобәйдулла Габдулла улы Мөэминов (1885–1912) – шагыйрь, педагог. Хәзерге Оренбург өлкәсенең Рәдүт (Никитино) авылында туган. «Кыйссалы вә хиссалы шигырьләр» (1907), «Гөлзаре сыйбиян» («Балаларга чәчәк түтәле», 1907), «Мәктәп өчен шигырьләр» (1909) исемле шигырь җыентыклары, «Табигатькә сәяхәт яки тарихи табигыйә» (1908), «Тәсһиле җәгърафия» («Гадиләштерелгән география», 1911) исемле дәреслекләр авторы.

[4] Хөсәенев Габделгани Мөхәммәтгали улы (1839–1902) – сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, иганәче.

кенә укучы җыела. Укучылар, белем дәрәҗәләренә карап, өч төркемгә бүленәләр. Курсларда мәктәптә укыла торган фәннәр генә өйрәтелеп калмый, мәктәптән тыш уку, милли театр, музыка, хатын-кызларның иҗтимагый вә хокукый хәле, хиҗаб һәм башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат та бирелә. Курслар ахырында имтихан уздырылып, Оренбург шәһәренең татар дөньясы өчен әһәмиятеле оешмаларына экскурсия дә оештырыла (Зиннәтуллина, 2019: 17). Шулай итеп, ун ел эчендә «Багъбостан мәктәбе» һәм җәйге курслар кысаларында барлыгы 347 мөгаллимә хәзерләнеп чыга.

Заманында «Багъбостан мәктәбе» һәм аның мөдирәсенең эшчәнлеге мөселман җәмәгатьчелегендә югары бәяләнгән. Мәсәлән, Габделхәмит Мөслими[5] үзенең Оренбургтагы татар кызлары өчен ачылган уку йортларын сурәтләгән мәкаләсендә бу мәктәптә белем бирү процессының югары дәрәҗәдә куелышына басым ясый, ә аның җитәкчесен иң сәләтле һәм булдыклы мөселман хатын-кызлары рәтенә кертә (Мөслими, 1915).

1918 елда исә Багъбостан ханымның педагогик эшчәнлегенең зур әһәмияткә ия булган өлешенә беркадәр нәтиҗә ясау, аны олылау йөзеннән «Ун еллык гыйльми хезмәт» дип аталган китапчык басылып чыга. Бу хезмәт Оренбург мөселман ханымнары җәмгыяте тарафыннан, мәктәпнең ачылуы һәм Багъбостан ханымның мәгариф юлында ун ел хезмәт куюы уңаеннан төзелә. Китапта Багъбостан ханым эшчәнлегенең тулы тарихы сурәтләнә: мәктәп эшчәнлеген оештыру мизгелләре, матди һәм мәгънәви ярдәм күрсәткән шәхесләр, укытылган фәннәр, һәр елны тотылган чыгымнар, укучылар саны, мөгаллимә ханымның ничек итеп укытучылык шәһадәтнамәсе алуы, Төркиягә сәяхәте, җәйге курслар һ.б. Моннан тыш, җәйге курсларда белемен арттырырга килгән Акмәчет хәйрия җәмгыяте мәктәбе мөгаллимәсе Һөрмез Мөхәммәдованың истәлекләре һәм Багъбостан ханымның Төркиягә сәяхәте вакытында булган вакыйгаларны яктырткан мәгълүмат урын алган.

*КУШЫМТАЛАР*

*Мөгаллимәләр курсы тәэсирияте (гайнән)*

«Без – Кырым, Акмәсҗед мөгаллимәләре бу сәнә хәмиятьле (*яклаучан*) затлар саясендә у (*ул*) дәрәҗә зыяландык вә истифадә итдеккә (*файдалануга*) аңлатмактан гаҗизем. Улҗә (*табыш*) хосусый уларак, бер кач (*берничә*) айлар укымышдым. Бу хосусый укуешы бәндә (*миндә*) пәк чок (бик) хисләр уяндырмышды. Милләтнең яртысыны кадынлар (*хатыннар*) тәшкил итдекене аңламышдым. Бу хисләреме дәһа зиядә (*тагы да*) тәүсигъ (*киңәйтү*) вә инкишаф итдерә (*ача*) белмәк өчен милләтнең анасы димәя шаян (*тиешле дәрәҗәле*) мөгаллимә Багъбостан ханымның тәртип итдеке мөгаллимәләр курсына җан атмышдым. Шу курса иштирак итмәк (*катнашу*) өчен Кырым – Акмәсҗет җәмгыять хәйриясе онытылмаз дәрәҗәдә ярдәм итдекендән, кәндесенә (*үзенә*) миннәтдарым (*рәхмәтлемен*). Ниһаять, мөгаллимәләр курсына килеп,

[5] Мөслимев Габделхәмит Гатаулла улы (1889–1937) – мәгърифәтче, мөгаллим.

мөгаллимәләремезе вә рәфикаләремезе күрәнҗә йөземез дәһа бер кат көлде. Сыйралар (*юллар*) үзәренә кичеп назик (*гүзәл*) сүзләр, мөәссир (*тәэсирле*) нотыклар дыңлаеп, бер кач көн соңра Оренбург шәһәре мәгарифпәрварләрендән “Вакыт” газетасы баш мөхәррире Фатих әфәнде Кәримов, Сөнгать әфәнде Бикбулатов, Габдулла Газиз әфәнде Сакмарый, башка мөхтәрәм затларның лекцияләрене дыңладыкемдә кәндемдә соң дәрәҗә бер мәсгудият (*рәхәтлек*) хисе идиюрдем. Ләкин шимали кардәшләремнең шивәләренә (*диалект*) ашна (*таныш*) улмадыгымдан, ибтидалары (*башлангычлары*) бераз диңеләеп дәвермеш исәм дә, нәзакятьле мөгаллимәләремездән Багбостан ханым, Төркестанлы Маһирә ханым, Троицк шәһәре дарелмөгаллимат мөгаллимәсе Сара ханымларның сәгый (*тырышлык*) вә гайрәтләре саясендә гүзәлчә алышып, аз заман эчендә чук файдаландым вә шимдидән (*моннан*) соңра кадын вә кызларның бәхтияр улачакларына, каралык зинданындан чыгып, сәрбәст (*ирекле, азат*) яшәячәкләренә өмидләр багладым. Мөгаллимә ханымнарымызә бөек дәрәҗә гарыз миннәтдары әйләдем.

Оренбург земствосының мөселманләрә билхасса (*махсус рәвештә*) мөселман мөгаллимәләре курсларына итдеке илтифат өчен дә тәшәккер (*рәхмәт*) әйтмәмәк мөмкин дәгелдер. Бән бу заманә кадәр земстволарың нә улдыгыны вә унларың хаиз (*җыйган*) улдыклары әһәмиятен пәк аз билиюрүм. Шимди (*хәзер*) исә боны да аңладым. Һәля, безем мөгаллимәләр курсына бирдеке әһәмият шаян тәкъдирдер. Оренбург земствосы мөгаллимәләр курсына күстәрдеке хәсән (*гүзәл*) нәзар (*игътибар*) сәясендә безләр сәяхәт иттек. Оренбург шәһәрене күрдек. Урадә гыйльми, фәнни, сәнагый (*сәнәгатькә караган*) мөәссәсәләре (*оешмаларын*) зиярәт әйләдек. Земствоның бу лотыфы да (*гүзәллеге дә*) һич оныдыламаз. Башда Оренбург земствосы мәгариф мөдире Березняков, земствоның мәгариф шөгъбәсе вә мөселман мәэмүрләрендән Ибраһим әфәнде Терегулов, Ибраһим әфәнде Бикчәнтәев вә зикер (*искә алган*) әфәнделәр үзәре земство идарәсенә вә Оренбург мөселманларына соң дәрәҗә мөтәшәрриф (*рәхмәтле*). Курсдан бөек истифадәләр иттек (файдалар алдык). Әүлән (*беренчедән*), Русиянең мохтәлиф (*төрле*) йирләрендән кәлән мөгаллимә рәфикаләремез лә күрешеп танышдык, сөйләшдек. Хиссиятемез лә пайлашдык (*бүлештек*). Саниян (*икенчедән*), шимали кардәшләремезнең гыйлем вә гыйрфанчә күстәрдекләре тәрәккыйләрене күреп, истикъбалемезең (*киләчәгебезнең*) өмидле улдыгына кальбләремезә (*йөрәкләребезгә*) иман тугъды. Салисән (*өченчедән*), шимали һәмширәләремезең бер баскычда улса, безләрдән югары улдыкларыны күреп мәмнүн улдык.

Акмәсҗед җәмгыять хәйрия мәктәбе мөгаллимәсе Һөрмез Мөхәммәдова. (Б. 14–15)

*Мәҗлестә элек ислам ханымы*

Дүн (*түбән, аскы*), мәбгусан (*депутатлар*) милләт. Һич өмид вә интизар итмәдекләре, ихтимал ки хатер (*хәтер*) вә хыялларындан бәйлә кәчирмәдекнәре мәмнүният. Бәхеш (*өлеш, бүләк*) бер йиңеллек каршысында калмышлар, сами-

гин миянымда (*сөйләүләренә күрә*), элек дәфга (*тапкыр*) уларак бер төрек вә мөселман ханымы күрмешләрдер.

Бу мөхтәрәм һәмширәмез Русиянең Оренбург шәһәрендәге төрек инас (*хатын-кыз*) мәктәбенең мөдирә вә мөгаллимәсе Багъбостан ханым әфәндедер ки, мәҗлесә бер мөгаллимәсе илә килмеш вә матбугат әҗнәбия (*чит*) ложасында әхез (*кабул итү, кулга алу*) мәүкыйгъ (*урын*) идәрәк, госманлы төрекләре кардәшләренең күндердекләре мәбгусларың мөзакәрәэне үзен мөддәт (*вакыт*) истимагъ (*тыңлау*) әйләмеш, мәҗлесә керән элек төрек ханымы улмак имтиязын (*башкалардан аерылып тору*) ихраз (*ирешү*) илә мәҗлес миллимезең тарихына карышмышлардыр.

Нә гүзәл бер хатирә...

(«Тасфире әфкяр», 1145 нөсхәсе) (Б. 16)

ЧЫГАНАКЛАР

*Мөслими Г.* Оренбургта кызлар мәктәбе // Вакыт. 1915. 3 апрель.

Ун еллык гыйльми хезмәт: Оренбург шәһәрендә беренче кызлар мәктәбе вә беренче мөгаллимәләр курсының мөәссисе вә мөдирәсе Багъбостан ханымның ун еллык бәйрәменә багышлана. Оренбург, 1918. 23 б.

ӘДӘБИЯТ

*Зиннәтуллина А.Ә.* “Мәктәп тотып үскән баллы Багъбостан ханым...” // Безнең мирас. 2019. №5. Б.16–22.

*Кудаш С.* Халкыбызның каһарман бер кызы // Казан утлары. 1984. №10. Б.164–169.

**Автор турында белешмә:** Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге фәнни хезмәткәре, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А., Казан, Россия Федерациясе); jamash.00@mail.ru

*Редакциягә керде 04.12.2023* *Кабул ителде 31.01.2024*

## БАГБУСТАН МУКМИНОВА И ЕЕ ШКОЛА ДЛЯ ДЕВОЧЕК В ОРЕНБУРГЕ (ПО МАТЕРИАЛАМ ВТОРИЧНОГО АНАЛИЗА)

***А.А. Зиннатуллина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*jamash.00@mail.ru*

Исследование приурочено к 140-летнему юбилею со дня рождения выдающейся представительницы татарского народа Багбустан Вильдановны Мукминовой (1884–1963). Она известная просветительница, педагог и автор многочисленных статей, посвященных женскому вопросу. Благодаря ей, в 1908 г. в Оренбурге открывается первая новометодная школа

«Школа Багбустан», которая функционирует до 1918 г. Багбустан ханум возобновляет летние педагогические курсы, созданные на рубеже XIX–XX вв. по инициативе Габдулгани Хусаинова в д. Кабаново Бурзян-Кипчакской волости Оренбургской губернии. Она одна из первых татарских женщин, получивших официальное свидетельство от Оренбургского Мусульманского Духовного Собрания, разрешающее педагогическую деятельность. Для изучения педагогического опыта и повышения образования Б.Мукминова в 1914 г. отправляется в Турцию. Здесь она добивается разрешения попасть в парламент и выступает перед местными депутатами. Это было неслыханное для Турции событие. Его осветила турецкая пресса.

В представленной статье озвучены факты биографии и главные направления педагогической деятельности Б.В. Мукминовой. Исследование основывается на вторичном анализе сведений из книги «Ун еллык гыйльми хезмәт», посвященной 10-летнему юбилею «Школы Багбустан» и педагогической работе ее руководителя. В книге, подготовленной членами Оренбургского мусульманского женского общества, описывается история «Школы Багбустан» с первых дней ее существования, упоминаются лица, оказавшие материальную и моральную поддержку школе, перечисляются преподаваемые предметы, раскрываются доходы и расходы учебного заведения, освещается работа педагогических курсов. В публикации подробно описывается поездка Багбустан ханум в Турцию, содержатся воспоминания учительницы Ак-Мечетской женской школы Хермез Мухаммедовой, которая являлась участницей летних педагогических курсов. Отдельное внимание уделяется заметке о Багбустан ханум из турецкой газеты «Тасфире афкяр».

**Ключевые слова:** Багбустан ханум, женское образование, педагогические курсы, Ак-Мечеть, Оренбург, Крым, Оренбургское мусульманское женское общество.

**Для цитирования:** *Зиннәтуллина А.Ә.* Багъбостан Мөэминова һәм аның Оренбургтагы кызлар мәктәбе (икенчел анализ материаллары нигезендә) // Историческая этнология. 2024. Т. 9. № 1. С. 61–67. DOI: 10.22378/he.2024-9-1.61-67

**Сведения об авторе:** Зиннатуллина Алсу Анваровна, научный сотрудник Центра истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); jamash.00@mail.ru

*Поступила 04.12.2023* *Принята к публикации 31.01.2024*

## BAGBUSTAN MUKMINOVA AND HER SCHOOL FOR GIRLS IN ORENBURG (BASED ON SECONDARY ANALYSIS MATERIALS)

***A.A. Zinnatullina***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*jamash.00@mail.ru*

The study is dated to 140$^{th}$ anniversary of the birth of the outstanding representative of the Tatar people, Bagbustan Vildanovna Mukminova (1884–1963). She is a well-known educator, teacher and author of numerous articles on women's issues. Thanks to her, in 1908 the first new-method school, the Bagbustan School, was opened in Orenburg, which operated until 1918. Baghbustan Khanum resumes summer pedagogical courses created at the turn of the 19$^{th}$ – 20$^{th}$ centuries on the

initiative of Gabdulgani Khusainov in the village of Kabanovo, Burzyan-Kipchak Volost, Orenburg Province. She is one of the first Tatar women to receive an official certificate from the Orenburg Muslim Spiritual Assembly, which allowed teaching activities. B. Mukminova went to Turkey in 1914 to study teaching experience and improve education. There she seeked permission to enter the parliament and spoke before local deputies. That was an unheard of event for Turkey and was covered by the Turkish press.

The presented article presents the biographical facts and principal directions of B.V. Mukminova’s pedagogical activities. The study is based on a secondary analysis of information from the book “Un ellyk gyilmi hezmat”, dedicated to the $10^{th}$ anniversary of Baghbustan School and its leader's pedagogical work. The book, prepared by members of the Orenburg Muslim Women’s Society, describes the history of the Bagbustan School from the first days of its existence, mentions people who provided material and moral support to the school, lists the subjects taught, discloses the income and expenses of the educational institution, and highlights the work of pedagogical courses. The publication describes in detail Baghbustan Khanum's trip to Turkey and contains the memoirs of the teacher of the Ak-Mechet girls’ school, Hermez Muhammedova, who was a participant in the summer pedagogical courses. Particular attention is given to the note about Baghbustan Khanum from the Turkish newspaper “Tasfire Afkar”.

**Keywords:** Bagbustan khanum, women’s education, pedagogical courses, Ak-Mechet, Orenburg, Crimea, Orenburg Muslim Women’s Society.

**For citation:** Zinnatullina A.A. (2024) Bagbustan Mukminova and her school for girls (based on secondary analysis). *Istoricheskaya etnologiya* [Historical Ethnology]. Vol. 9. No. 1: 61–67. DOI: 10.22378/he.2024-9-1.61-67 (In Tat.)

REFERENCES

Qudash S. (1984) The heroic daughter of the people. *Kazan utlary* [The lights of Kazan]. No.10: 164–169. (In Tat.)

Zinnatullina A.A. (2019) The famous educator Bagbustan khanum. *Bezneñ miras* [Our legacy]. No.5: 16–22. (In Tat.)

**About the author:** Alsou A. Zinnatullina is a Research Fellow at the Center of History and Theory of National Education, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); jamash.00@mail.ru

*Received December 4, 2023* *Accepted for publication January 31, 2024*